**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЛАЛАР ИЖАТ ҮЗӘГЕ**

# Күренекле шәхесләр

Теләче 2015 ел

# Кереш

Узган гасырның 70-80 елларында Югары Кибәхуҗа мәктәбендә белем алган укучыларның хәзерге көндә югары квалификацияле эшчеләр, педагоглар, инженерлар, юристлар,артистлар,җырчылар,хокук саклау органы вәкилләре булып уңышлы эшләүләре бик горурландыра.

Теләче районының Югары Кибәхуҗа авылында туып-үскән, анда хәреф танырга өйрәнеп, тәүге белемнәрен алып, олы дөньяга чыккан һәм дан казанган шәхесләр аз түгел.



# Эчтәлек

1.Кереш…………………………………...2 бит
2.Фәрит Хатыйпов………………...….3 –4бит
3.Марсил Кадиров………………………5 бит
4.Фәрит Салихов………………………..6 бит
5.Васил Гарифуллин……………………7 бит
6.Мәхмут Максуд…………………  …..8 бит
7.Мәхмүт Хасанов………………  …….9 бит
8.Рәсим Низамов………………  ……...10бит

**Рәсим Низамов** ,
жырчы



## ЧЫН ХАЛЫКЧАН ЖЫРЧЫ

Рәсим Низамов 1973 елның 1 декабрендә Татарстанның Теләче районы Төрек–Тәмте авылында дөньяга килә. Авылның сигезьеллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, биш чакрым ераклыктагы күрше Югары Кибәхуҗа авылына йөреп укый.

4-5 сыйныфларда укыганда ук үзе гармунда уйнап, үзе җырлый. Мәктәптә үткәрелә торган бер генә кичәләр дә Рәсимнең җырларыннан, гармун моңнарыннан башка үтми.


1991 елда мәктәпне тәмамлаганнан соң, укытучы булырга теләп, Рәсим Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетына укырга керә. 1993 елда студентлар арасында уздырылган “Ягымлы яз” фестивалендә катнашып, өченче дәрәҗә дипломга, ә 1997 елда “Татар җыры” конкурсында “Өченче көн тоташ кар ява” (М.Кәрим сүзләре, С.Садыйкова көе) җырын башкарып, беренче дәрәҗә дипломга лаек була. Башкортстанның Нефтекамск шәһәрендә узган “Дуслык җыры-98” фестивалендә катнашып, ул тагын беренче дәрәҗә иясе була.

Институтны тәмамлагач, яшь башкаручы Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге ансамбльгә эшкә керә. Анда бер ел эшләп, тәҗрибә туплаганнан соң, ул үз группасын оештыра. Рәсим соңрак Казан дәүләт консерваториясенең вокал бүлеген уңышлы тәмамлый,.“Салават” җыр театрында уңышлы гына эшли.

Рәсим Низамов башкаруында радио-телевидение аша да еш яңгыраган “Сагындым сөйгәнемне” (Х.Мөдәрисова сүз., М.Газетдинов көе), “Рамбар юллары” (татар халык җыры), “Хат язармын дигән идең” (Р.Миңнуллин сүз., Ф.Хатыйпов көе), “Яшик әле, Теләчем” (Р.Миңнуллин сүз., Ф.Мортазин көе), “Авыл карлыгачлары” (Х.Әюпов сүз., Р.Вәлиев көе) кебек җырларны халык яратып кабул итте, үз итте, хит дәрәҗәсендә күтәрде.

Бүгенге көндә Рәсим тамашачыга яңадан-яңа матур җырларын бүләк итеп тора.





Фәрит Хатипов,
композитор,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

## ЯЛКЫНЛАНЫП ИҖАТ ИТӘМ

Мин 1948 елның 1 гыйнварында Теләче районының бик матур табигатьле, тәмле сулы чишмәләргә бай булган Югары Кибәхуҗа авылында туганмын. Балачак һәм мәктәп елларым әлеге авылда үтте, кечкенәдән гармун-баян белән җенләндем. Әтием дә оста гармунчы булган, шулай ук әнием ягыннан да барысы да җыр-моңны үз иткәннәр. Сәнгатькә гашыйк булу миңа нәселдән күчкәндер, диясем килә.

Һәркемнең күңелендә иң истә кала торганы, мөгаен, мәктәп елларыдыр. Әйтергә кирәк, безнең Югары Кибәхуҗа мәктәбенең укытучылар коллективы үсеп килүче яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә көчләрен кызганмадылар. Класста һәм класстан тыш чараларда белем алуга омтылыш тәрбияләп, киләчәктә Илгә-көнгә кирәкле кешеләр булып үсүебезне теләделәр.

Районда үткәрелә торган бер генә кичәдән дә без читтә калмадык, актив катнаштык. Сыйныф җитәкчебез Заһир абый Сөнгатуллин төрле спорт ярышларына алып йөрде. Миндә спортка мәхәббәт, мөгаен, шул мәктәп елларыннан сеңеп калгандыр. Рәсем сәнгате белән мавыгуым да – укытучыларымның үз фәненә мәхәббәт тәрбияләве нәтиҗәседер диясем килә.

Концерт-смотрларда катнашып, гел призлы урыннарга лаек булдык. Фестивальләр күңелләрдә мәңге онытылмаслык уелып калырлык итеп үткәрелә иде. Пионерлар белән яккан учаклар, мәктәп еллары, файдалы гамәлләр гомер буе истә калырлык булды. Спектакльләр куеп авылдан-авылга йөри идек. Мәктәптә озын тәнәфестә гармун уйнап биетүне дә бик теләп башкара идем, тәнәфесләр искиткеч күңелле үтә иде.

Шул елларда мин үземә белем һәм тәрбия биргән укытучыларыма чиксез рәхмәтле. Алар безне әхлаклы, чын кешеләр итеп тәрбияләү өчен зур көч куйдылар.

Мәктәптә рус теле һәм әдәбияты, җыр дәресләрен укыткан Галия апа Газизовага аерым тукталып үтәсем килә. Минем сәнгать дөньясына тартылуымның чишмә башы Галия апага барып тоташа. Ул башы-аягы белән сәнгатькә гашыйк кеше булганлыктан, вакытында минем сәләтемне күреп алып, миңа юл күрсәтүче булды. Ул миңа олы сәнгать дәрьясына кереп китү өчен юнәлеш бирде. Музыка өлкәсенә кереп китүемә зур этәргеч булды. Мин гомерем буе бу остазыма рәхмәтле булып яшим.

Казан музыка училищесын уңышлы тәмамлап, бөтен гомеремне музыкага, җырга багышладым, гармун-баян минем аерылмас юлдашым булды.

Баянчы буларак, җырчылар белән тыгыз элемтәдә булуым да көйләр язарга ярдәм иткәндер.

Баянчы-аккомпаниатор булуым белән бергә үз өстемдә тырышып эшләп, бик күп җырлар язып, композитор булып танылдым.

Мин бик күп шагыйрьләр белән тыгыз элемтәдә торам. Көй язасы шигырьне тирәнтен аңлап укыйм, ул шигырьгә хас көй эзләп табам, шигырь белән көйнең тәңгәллегенә ирешкәндә генә җыр уңышлы килеп чыга. Ә кайвакытта башта көй туа, ә аннан соң шул көйгә сүзләр яздырып алам. “Һаман яратам “дигән җыр шулай туды. Шагыйрь Зөлфәт аңа шигырь язып бирде.

Иҗатымдагы уңышлар озак көттермәде, миңа “Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе” дигән мактаулы исем бирелде.

Бүгенге көндә биш китабым дөнья күрде. Аларда 500 дән артык җыр тупланган: “Һаман яратам”, “Моңлану”, “Парлы гашыйк”, “ Синең нурың”...

Татарстанның атказанган артисты Рабига Сибгатуллина белән гаилә корып, бер ул тәрбияләп үстердек.

Рабига белән Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясендә 35 елдан артык бергә-бергә эшләп бик күп гастрольләрдә йөрдек.

Теләчене, туган авылым Кибәхуҗаны, авылыбыз мәктәбен, укытучыларын бик яратам, һәрчак сагынып яшим. Сабантуйларга кайтам, туган җирдән иҗатыма илһам алып киләм.

Әле дә яңа җырлар туып тора, Ходай исәнлекне генә бирсен, ялкынланып иҗат итәм.





**Мәхмүт Хәсәнов** , язучы

## ТУКАЙ БҮЛӘГЕ ИЯСЕ

Мәхмүт Максуд улы Хәсәнов 1927 елның 21 декабрендә Татарстан АССРның Саба районы (хәзерге Теләче районы) Югары Кибәхуҗа авылында крестьян гаиләсендә туа. 1927 елда алар гаиләләре белән Зеленодольск шәһәренә күченә. Шунда Мәхмүт татар мәктәбенә укырга керә, Бөек Ватан сугышы чорында һөнәр училищесын тәмамлап, берникадәр вакыт слесарь булып эшләргә туры килә, аннары янә урта мәктәптә укуын дәвам иттерә. Әдәбиятка, театр сәнгатенә балачактан ук кабынган мәхәббәт 1944 елда уналты яшьлек егетне Мәскәүгә – А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтына (ГИТИСка) алып килә. 5 елдан соң, институтның актерлык факультетын тәмамлап, Мәхмүт Хәсәнов Казанга кайта һәм Яшь тамашачылар театрында (ТЮЗда) актер булып эшли башлый. Бер елдан аны Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында уйнарга чакыралар. Шул чорда (1945-51) елларда очерклар, хикәяләр авторы буларак газета-журнал битләрендә дә еш күренә башлый. Ахырда ул, актерлык хезмәтен ташлап, бөтенләй журналистика өлкәсенә эшләргә күчә: “Совет Татарстаны” (хәзерге “Ватаным Татарстан”) газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннары 1952-55 елларда Татарстан радиосында хәбәрче вазифасын башкара.

1957 елда Мәскәүдә СССР Язучылар Союзы каршындагы ике еллык Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, М.Хәсәнов Питрәч районы газетасы редакциясендә эшләп ала.

1959 елда Азнакай эшчеләр поселыгына күчеп китеп, ике дистәдән артык шунда яши һәм эшли.

1965 елдан – СССР Язучылар Союзы члены.

1977 елда аңа “Татарстан АССРның атказанган культура работнигы” дигән мактаулы исем бирелде.

“Язгы аҗаган” (1987) романы исә язучының киң колачлы иҗатының кибән башы булды һәм моның өчен аңа Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә (1988).



**Мәхмүд Максуд ,**
язучы, публицист һәм тәрҗемәче

## ТУГАН ИЛ ҖЫРЧЫСЫ

Күренекле язучы, публицист һәм тәрҗемәче Мәхмүд Максуд 1900 Теләче районының Югары Кибәхуҗа авылында Гыйсаметдин хәзрәт гаиләсендә дөньяга килә. Беренчел белемне әтисеннән алып, аннан ары Кышкар мәдрәсәсенә урнаша һәм биш ел дәвамында, 1909-1914 елларда, шул танылган уку йортында белемен чарлый. Мәхмүд, атасы Гыйсаметдин хәзрәт кебек, китап укуны ярата. Хәтере яхшы булу сәбәпле, олан укыган әсәрләрен аңына сеңдереп җиңел үзләштерә. Әле бала чагында яттан белгән Коръән сурәләре янына ул дөньяви китаплардан алган мәгълүматларны да сыйдыра.

Хәзрәт заман сулышын яхшы аңлаган кеше була, шуңа да оланын Арчадагы рус-татар мәктәбенә биреп, анда ике ел дәвамында рус телен һәм дөньяви мәгълүматлар, тормыш кануннарын өйрәтә. 1918 елның җәйге айларының берсендә Мәхмүд Мәскәүгә китеп урнаша. Анда ул танылган язучы Галимҗан Ибраһимов белән бергә ана телебездә чыга торган “Чулпан” газетасында эшли. Биредә эшләү аның иҗади сәләте – әдиплеге ачылуына төп сәбәпче була. “Чулпан”да язучының беренче хикәясе – “Бәйрәм җитә” дөнья күрә.

1919 елны Мәхмүд Максуд үз теләге белән Кызыл гаскәргә языла һәм адмирал Колчакка каршы сугышта катнаша. Биредә аның бик күп шигырьләре туа һәм фронт газеталары битләрендә дөньяга игълан ителәләр. “Кызыл йолдыз”, икенче дәрәҗәле “Ватан сугышы” орденнары, дүрт сугышчан медальгә лаек була. Сугыш вакытында язган әсәрләре татар лачыннарын дошманга каршы батыр сугышка аяусыз көрәшкә күтәрде. Ул елларда шагыйрьнең “Үз һәм нәләт җыры” дигән шигырьләр җыентыгы солдатлар арасында киң популярлык казанган китаплардан иде.

Г.Ибраһимов, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Ф.Кәрим һ.б. әдипләребез иҗатына караган язмаларында ул үзен тирәнтен әдәбиятны белеп, төпле фикер әйтә белүче киң эрудицияле зыялы итеп танытты.





Марсил Кадыйров,
1970 еллар укучысы,
химия фәннәре докторы, КТУ доценты,
ТР ның атказанган тренеры,
Татарча көрәш федерациясенең президиум әгъзасы,

Башлангыч мәктәп без үскәндә Түлешкәдә урнашкан иде. Шушы уртача авыл йорты кадәр бинада безне дүрт сыйныфны берьюлы Гайшә апа Борһанова укыта иде. Мин беренче сыйныфка кергәндә без дүрт сыйныфка унике укучы җыелдык. Бәйрәмнәргә авыл халкына концертлар әзерләп куя идек. Яңа ел бәйрәмнәре бик күңелле үткәнлеге хәтердә калган.

Бишенче сыйныфка дүрт чакрымдагы Югары Кибәхуҗа урта мәктәбенә йөреп укый башлыйбыз. Безнең сыйныфта 36 бала булып, шуның 29 ы малайлар иде. Сыйныф җитәкчебез Равил абый Гәләвиев безнең белән бөтен көчен, тырышлыгын биреп эшли иде. Аның тормыш иптәше Гөлниса апа физикадан укытты. Алга таба минем физик булып китүемнең нигезләрен нәкъ менә Гөлниса апа салды инде.

1973 елда Арчага күчеп китеп, Арчаның 2 нче мәктәбендә укыганда, мин 8-10 нчы классларда Арча районында физика буенча олимпиадаларда призлы урыннан төшкәнем булмады, ә 10 нчы сыйныфта хәтта беренче урынга да чыктым. Ул вакытта Арча районында физика буенча Кенәр мәктәбе бик көчле иде. 1976 елда Казан дәүләт университетының физика факультетына Кенәр мәктәбен тәмамлаган өч егет минем белән бергә укырга керде һәм аны уңышлы гына тәмамлап чыкты. Арча мәктәбендәге сыйныфта исә миңа уку буенча реаль конкуренция юк иде. Бу миңа бик сәер тоелды, чөнки Югары Кибәхуҗа мәктәбендә без өч малай – Резиль Әхмәтгалиев, Васил Яруллин һәм мин – бер-беребез белән ярышып, бик яхшы укыдык. Резиль белән Васил да КДУның механика-математика факультетына укырга керделәр.

Югары Кибәхуҗа урта мәктәбендә бик кызыклы гына гуманитар чаралар да уздырыла иде. Язын “Кошлар көне” бик массалы рәвештә һәм күңелле үтә иде. Бишенче сыйныфта ук инде мин шушы чарада язга багышланган шигырь язу һәм рәсем ясау бәйгеләрендә җиңеп чыккан идем. Шул ук елны мине пионер дружина шурасы рәисе итеп куйдылар. Дружина линейкаларында кеп-кечкенә буем белән (физкультура дәресләренә тезелгәндә ахырдан икенче булып басып тора идем) зур-зур отряд командирларыннан рапорт кабул иткәнлегем истә калган.



Фәрит Салихов,
журналист.

## МӘКТӘП БЕЗНЕ ТӨЗӘТТЕ, ҺӘМ ЯШӘРГӘ ӨЙРӘТТЕ…

Тәүге кабат мәктәпкә аяк баскан елларымны күп тапкырлар хәтердә яңартырга тырышсам да, шул чактагы кыңгырау чыңын һич кенә дә колакта яңгырата алмый интегәм. Алай гына да түгел, кайберәүләрнең: “Укытучымның кулдан тотып язарга өйрәтүен сагынам”, — дигән сүзләре дә, турысын әйтим, ачуымны кабарта әле минем. Чөнки кеше гомеренең иң күңелле әлеге мизгелләре үземнең тамчы да исемдә калмаган. Шуңа да андый чакта башкалар сүзенә кушыла алмый иза чигәм. Хәер, аның каравы төрле истәлек һәм хатирәләрне алыштырырлык башка хис-кичерешләр куандыра мине. Әйе, әйе — мәктәптә тәүге тапкыр кыңгырау чыңлаганын, укытучымның кулдан тотып язарга өйрәткәнен хәтерләмәсәм дә, мәктәп елларының беренче сыйныфтан ук күңелгә кереп урнашкан үзгә бер җылылыгы гомер буе дәрт-дәрман биреп килде. Әлеге җылылыкны булдырган учакка беренче сыйныфтан ук җан өрелгән, еллар дәвамында утын өстәлгән булырга тиеш. Чөнки җылысы куәтле. Мәктәбемнең зур бәйрәме алдыннан кабат шул җылылыкны тоемларга җай чыгуына сөенеп куйдым әле менә.

Мәктәбемдә белем алып чыккан башка авылдашларым үпкә белдерәсен белсәм дә, горурланып: “Безнең сыйныф мәктәп тормышында иң чая, иң алдынгы, һәм шул ук вакытта иң артта калган сыйныф та була белде”, — дип әйтә алам. Бөтен мөмкинлекләрен эшкә җигеп алдынгылыкны яулый алган сыйныфның, икенче көнне үк арткы сафларда булуы да укучының үзгә бер таланты булган икән ул.






## ЖУРНАЛИСТЛАР ДЕКАНЫ

Васил Гарифуллин,
Казан (Идел буе) федераль
университеты деканы,
профессор

Ул Теләче районы Югары Кибәхуҗа авылында 1961 елның 1 октябрендә дөньяга килә.

Васил Гарифуллин кече яшьтән үк туган телне һәм әдәбиятне яратып үсә, иҗатка тартыла, шигырьләре һәм мәкаләләре белән республика балалар матбугатында, район газетасы битләрендә чыгыш ясый, язучы Газиз Нәбиуллин җитәкләгән “ Мишә дулкыннары ” әдәби берләшмәсендә шөгыльләнә.

Мәктәптә, авыл клубында бик күңелле очрашулар үткәргән. Казанга кайткач, “Яшь ленинчы” да шушы сәяхәте турында бик матур гына бер язма бастыра: “Васил хикәя-шигырьләр язарга бик ярата. Ләкин аның әсәрләрен нигәдер газета-журналларда бастырмыйлар.Үҗәтләнеп шулай яза торгач, бастыра башларлар әле. Кем белә, аңардан берәр язучы яки журналист та чыгып куяр. Чыкмаса, бөтен кешегә дә язучы булып бетәргә димәгән. Иң мөһиме: яхшы кеше булсын.” Менә шуннан соң булачак галимнең беренче хәбәре басылып чыга.

Журналистикадан теоретик белемнәрен тагын да тирәнәйтү максатыннан, 1986 елда Казан дәүләт университетының аспирантурасына укырга керә. Күренекле галимә Диләрә Гариф кызы Тумашева мәктәбен узганнан соң, 1990 елның февралендә яшь галим Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы советта кандидантлык диссертациясе яклый.

1999 елның гыйнварында Васил Гарифуллин Казан дәүләт университетының татар журналистикасы кафедрасы мөдире итеп сайлана. 2000 елның март аенда Васил Заһит улы Гарифуллинга профессор дигән гыйльми исем бирелә. 40 яше тулганчы ул профессор дәрәҗәсенә ирешә. 2002 елның гыйнвар аенда Васил Заһит улы КДУның журналистика, социология һәм психология факультеты деканы итеп сайлана.

Татарстан Журналистлар берлеге президиумы әгъзасы буларак, үзенең журналистик һәм публицистик эшчәнлеге белән дә Васил Заһит улы республиканың иҗтимагый тормышында актив катнашып килә.